## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАКЫРЧЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

24 апрель, 2023 ел №76

**«Җир салымы турында»гы карарга үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлегенә ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Бакрчы авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Бакырчы авыл җирлеге Советының 14.11.2014 № 105 «җир салымы турында» карарына үзгәреш кертергә, 6 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Календарь елның беренче кварталы, икенче кварталы һәм өченче кварталы салым түләүче-оешмалар өчен хисап чоры дип таныла.».

2. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Бакырчы авыл җирлеге советының «җир салымы турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 8 ноябрендәге 63 номерлы карарына үзгәреш кертергә, 3 пунктны «һәм аннан соңгы салым чорлары»сүзләре белән тулыландырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) (PRAVO.TATARSTAN.RU).

4. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

**Бакырчы авыл**
**җирлеге башлыгы** **Ф.Х.Валиев**